**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2020 Балык Бистәсе штп. №221пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 сентябрендәге “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия турында” 147пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 июлендәге “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 1120 номерлы карарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 сентябрендәге “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия турында” 147пи номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 23.03.2018 ел 57пи, 05.10.2018 ел 236пи, 19.03.2019 ел 107пи номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәгә:

1.1.1) 4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 47 номерлы карарының (2020 елның 27 июлендәге ред.) I пунктының

икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән органнардан һәм (яисә) оешмалардан тыш, торак урын милекчесе (ул вәкаләт биргән зат) комиссиягә киңәш бирү тавышы хокукы белән эшкә җәлеп ителә һәм аңа комиссиянең утырыш вакыты һәм урыны турында Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы яисә комиссияне төзегән җирле үзидарә органы билгеләгән тәртиптә хәбәр ителергә тиеш. Гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән торак урын милекчесенең комиссия эшендә катнашу тәртибе комиссияне төзегән Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә."

1.1.2) 4.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Комиссия әгъзаларының тикшерүдә катнашуы, алар комиссия составына кертелгән очракта, мәҗбүри була.";

1.1.3) 4.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 абзац өстәргә:

"Әгәр комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми санының кимендә яртысы, шул исәптән дәүләт күзәтчелеге (контроле) органнарының, архитектура, шәһәр төзелеше органнарының һәм тиешле оешмаларның барлык вәкилләре, комиссия составына кертелгән экспертлар катнашса, Комиссия карар кабул итәргә хокуклы (кворум бар)."

1.1.4) 4.8 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Алынган бәяләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләнгән тәртиптә бәяләмә алган көннән алып 30 календарь көн эчендә кабул итә, ә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән торак урыннарны тикшергән очракта, бәяләмә алган көннән алып 10 календарь көн эчендә ул билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы "Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 47 номерлы карарының 7 нче пунктындагы җиденче абзацында каралган (27.07.2020 ел редакциясендә) карарны кабул итә һәм, йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип танылган очракта яисә ремонт-торгызу эшләрен уздыру кирәклеге турында тану очрагында, бинаны алга таба файдалану турында, физик һәм юридик затларны күчерү срокларын күрсәтеп, күрсәтмә (боерык) чыгара."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов